**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Татар Димскәе авыл җирлеге составына керүче Татар Димскәе авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында Карар**

**17 декабрь 2021 ел № 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Татар Димскәе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кеше өчен, 2022 нче елда үзара салым кертүгә 300 (өч йөз) сум күләмендә килешәсезме? мәсьәләсе буенча 2021 елның 17 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, күп балалы гаиләләрдән тыш җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү:
- Татар Димскәе авылын төзекләндерү

ЮК ,ӘЙЕ".

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 369 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 194 кеше теркәлгән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 194 кеше тавыш бирде;
«юк» позициясе өчен - җыенда катнашучылар-0;
халык җыенында катнашучыларның 0-се тыелып калды.Р

Бәян ителгәннәр нигезендә, **халык җыены карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Татар Димскәе авыл җирлеге составына керүче Татар Димскәе авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип таныргa.

2. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Татар Димскәе авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кеше өчен, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, күп балалы гаиләләрдән тыш, 2022 нче елда үзара салым кертүне 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме?(Татар Димскәе чишмәсенә капиталь ремонт өчен)дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татар Димскәе авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының "Интернет" челтәрендә рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә. http://bugulma.tatar.ru - "авыл җирлекләре"бүлегенең "татар Димскәе авыл җирлеге" бүлекчәсе;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче,**
**Татар Димскәе авыл җирлеге башлыгы Л. А. Хәбирова**